| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.10.2025 ел Татар Кандыз авылы №16

Татар Кандызы авыл җирлеге
территориясендә йорт хайваннарының
урамда йөрү урыннарын билгеләү турында

Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «йорт хайваннарын тотуга өстәмә таләпләр раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары нигезендә шул исәптән аларны Татарстан Республикасы территориясендә йөртүгә", йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклауны тәэмин итүче Татар Кандызы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарны, аларның хуҗалары күзәтүе астында, Татар Кандызы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртергә рөхсәт ителгән урыннар итеп билгеләргә:

- Татар Кандызы авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә Совет урамы буйлап 200 метр ераклыкта (координатлары 54.129020, 53.150470);
- Татар Кандызы авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Ямашев урамыннан 200 метр ераклыкта (координатлары 54.137065, 53.132845);

- Татар Кандызы авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә 300 метр ераклыкта Әхмәтҗанов урамы буйлап (координатлары 54.126616, 53.102478)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе М. Ш. Насыйбуллин